КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 сентябрь г.Казань № 770

Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия төзү турында

Россия Федерациясе субъектларын социаль-икътисадый үстерүнең иң яхшы тәҗрибәләре һәм инициативалары буенча бөтенроссия конкурсының региональ этабын оештыру һәм үткәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия (алга таба – Ведомствоара региональ комиссия) төзергә.

2. Ведомствоара региональ комиссия турындагы нигезләмәне һәм аның составын (карарга теркәләләр) расларга.

3. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына Россия Федерациясе субъектларын социаль-икътисадый үстерүнең иң яхшы тәҗрибәләре һәм инициативалары буенча бөтенроссия конкурсында катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан бирелә торган гаризаларны җыюны тәэмин итәргә.

4. Ведомствоара региональ комиссиягә Бөтенроссия конкурсы Попечительләр советының 2018 елның 23 маендагы 2 номерлы беркетмәсе белән расланган Россия Федерациясе субъектларын социаль-икътисадый үстерүнең иң яхшы тәҗрибәләре һәм инициативалары буенча бөтенроссия конкурсы турындагы нигезләмә белән билгеләнгән вакытларда Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү

буенча тәкъдим ителгән тәҗрибәләрне һәм инициативаларны конкурс номинацияләре нигезендә сайлап алуны үткәрергә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 12 сентябрь, 770 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия (алга таба – Ведомствоара региональ комиссия) Татарстан Республикасын иң яхшы тәҗрибәләр доноры – төбәге буларак билгеләү максатларында оештырылган даими эшләүче ведомствоара күмәк орган булып тора.

1.2. Ведомствоара региональ комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы законнарына, Бөтенроссия конкурсы Попечительләр советының 2018 елның 23 маендагы 2 номерлы беркетмәсе белән расланган Россия Федерациясе субъектларын социаль-икътисадый үстерүнең иң яхшы тәҗрибәләре һәм инициативалары буенча бөтенроссия конкурсы (алга таба – Бөтенроссия конкурсы) турындагы нигезләмәгә, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.3. Ведомствоара региональ комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2. Ведомствоара региональ комиссиянең төп бурычы һәм функцияләре

2.1. Ведомствоара региональ комиссиянең төп бурычы –уңышлы региональ тәҗрибәләрнең һәм инициативаларның Бөтенроссия конкурсында катнашуын тәэмин итү.

2.2. Ведомствоара региональ комиссия, үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында, Бөтенроссия конкурсының региональ этабын оештыру һәм үткәрү буенча түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

һәр номинациядә Бөтенроссия конкурсы тәҗрибәләрен һәм инициативаларын Бөтенроссия конкурсы турындагы нигезләмәгә таянып сайлап алу;

ведомствоара региональ комиссия җитәкчесе тарафыннан кул куелган региональ сайлап алу нәтиҗәләре беркетмәсен рәсмиләштерү;

Татарстан Республикасыннан Бөтенроссия конкурсында катнашу өчен бердәм гариза әзерләү һәм формалаштыру.

3. Ведомствоара региональ комиссиянең хокуклары

3.1. Ведомствоара региональ комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Ведомствоара региональ комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләрен чакырырга;

үз компетенциясе чикләрендә Ведомствоара региональ комиссия тарафыннан карарлар кабул итү өчен кирәк булган мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, федераль дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарыннан, җәмәгать һәм башка оешмалардан соратып алырга;

үз бурычларын һәм функцияләрен законнар нигезендә үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән башка хокукларны гамәлгә ашырырга.

## 4. Ведомствоара региональ комиссиянең эш тәртибе

4.1. Ведомствоара региональ комиссия утырышлары аның җитәкчесе (җитәкче урынбасары) карары буенча үткәрелә. Ведомствоара региональ комиссия әгъзалары утырыш үткәрү турында тәкъдимнәр кертергә һәм көн тәртибен тәкъдим итәргә хокуклы.

4.2. Ведомствоара региональ комиссия җитәкчесе (җитәкче урынбасары) утырышларда рәислек итә, утырышны үткәрү көнен һәм көн тәртибен раслый, эшне планлаштыра һәм Ведомствоара региональ комиссия карарларын тормышка ашыруны тикшерүдә тота.

4.3. Ведомствоара региональ комиссия эшендә аның составына керми торган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләре катнаша ала.

4.4. Утырышлар йөзгә-йөз тавыш бирү формасында һәм читтән торып тавыш бирү юлы белән үткәрелә. Карарлар комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән йөзгә-йөз (ачык яки ябык) тавыш бирү формасында яки читтән торып тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Утырыш формасы һәм йөзгә-йөз тавыш бирү формасы Ведомствоара региональ комиссия җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан билгеләнә. Тавышлар тигез булганда рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

4.5. Ведомствоара региональ комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм аңа утырыш үткәрелгән көннән өч эш көне эчендә Ведомствоара региональ комиссия җитәкчесе тарафыннан имза куела.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 12 сентябрь, 770 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү буенча уңышлы тәҗрибәләрне һәм инициативаларны сайлап алу буенча ведомствоара региональ комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, ведомствоара региональ комиссия җитәкчесе |
| Габделганиев Фәрит Солтан улы | Татарстан Республикасының икътисад министры, ведомствоара региональ комиссия җитәкчесе урынбасары |
| Ярмоленко Алёна Александровна | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының инвестиция эшчәнлеге бүлеге башлыгы, ведомствоара региональ комиссия секретаре |

Ведомствоара региональ комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Агиев Шамил Рәхим | «Татарстан Республикасының Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге рәисе (килешү буенча) |
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасының мәдәният министры |
| Борһанов Рафис Тимерхан улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры |
| Газизов Азат Хәлил улы | «Россия таянычы» гомумроссия иҗтимагый кече һәм урта эшмәкәрлек оешмасының Татарстан төбәк бүлеге рәисе, җаваплылыгы чикләнгән «Казан сәүдә-сәнәгать предприятиесе» җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |

| | |
|---|---|
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасының хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Метшин Илсур Рәис улы | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Пахомов Алексей Михайлович | «Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе» төбәк берләшмәсе генераль директоры (килешү буенча) |
| Садыйков Марат Наил улы | Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры |
| Ирек Фәйзуллин Әнвәр улы | Татарстан Республикасының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасының яшьләр эшләре министры |
| Шәйхутдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры. |